**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫНЫҢ III ЧАКЫРЫЛЫШ XXXIX СЕССИЯСЕ**

**КАРАР №163**

Мөслим «13» декабрь 2019 ел

**Финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетының максатчан билгеләнештәге субсидияләре (башка бюджетара трансфертлар) торган авыл жирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 нче статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мослим муниципаль районы Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетының максатчан билгеләнештәге субсидияләре (башка бюджетара трансфертлар) торган авыл жирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибен расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан Мөслим муниципаль районы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольда тотуны Мөслим муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе Н.А. Бубековага йөкләргә.

Мөслим муниципаль район
Башлыгы, Мөслим муниципаль
район Совет рәисе Р.Х. Муллин

Татарстан Республикасы Мөслим
муниципаль районы Советының
2019 елның «13» декабрендәге
163 санлы карарына 1 нче кушымта

Финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетынын максатчан билгеләнештәге субсидияләре (башка бюджетара трансфертлар) торган авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибе турында

1. Әлеге кагыйдәләр Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар) бирүнең максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар түбәндәге формада бирелә:

1) Мөслим муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренен бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә муниципаль район бюджеты составында төзелә торган авыл җирлекләренә район финанс ярдәме фондыннан дотацияләр;

2) финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнеше субсидияләр булган авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар.

3) Россия Федерациясе Бюджет Кодексынын 133 статьясында билгеләнгән очракларда субвенцияләр рәвешендә;

4) Россия Федерациясе Бюджет кодексынын 142.2 статьясында билгеләнгән очракларда субсидияләр рәвешендә;

5) башка дәрәҗәдәге хакимият органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен, шул исәптән төбәк һәм муниципаль программалар буенча аерым чараларны үтәүгә авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар;

6) төзелгән килешүләр нигезендә муниципаль районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен авыл жирлекләре дәрәҗәсенә тапшырганда, аларны хәл итү буенча вәкаләтләрнен бер өлешен гамәлгә ашыруга авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар.

3. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы бюджетына түбәндәге максатларга бирелә торган субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) акчалары исәбеннән бирелә:

1) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 137 статьясы нигезендә, җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр (алга таба – дотацияләр), җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда, Мөслим муниципаль районы бюджетында Мөслим муниципаль районы авыл җирлекләренең финанс мөмкинлекләрен тигезләү максатларында карала.

Мөслим муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр Мөслим муниципаль районы составына керүче җирлекләргә Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы таләпләре нигезендә кабул ителә торган чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет турында Мөслим муниципаль районы Советы карары нигезендә бирелә.Авыл җирлекләренен бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә

муниципаль район бюджетыннан дотацияләр авыл җирлекләренә финанс ярдәменен район фондын барлыкка китерә.

Авыл җирлекләренен бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә муниципаль район бюджетыннан дотация күләме Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.9 статьясында (1 нче кушымта) каралган исәпләү методикасы нигезендә билгеләнә.

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Мөслим муниципаль районы бюджетыннан дотацияләрнен гомуми күләмен билгеләү һәм аларнын җирлекләр арасында бүленеше тәртибе Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы таләпләре нигезендә билгеләнә.

Мөслим муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләме һәм аларнын бүленеше чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджеты турындагы Мөслим муниципаль районы Советы карары белән раслана. Әгәр Мөслим муниципаль районы бюджеты проекты чираттагы финанс елына һәм план чорына расланса, план чорына авыл җирлекләре арасында бүленмәгән бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен, муниципаль район бюджетыннан план чорынын беренче елына расланган күрсәтелгән дотацияләрнең гомуми күләменең 20 проценттан артмаганын һәм план чорынын икенче елына расланган күрсәтелгән дотацияләрнең гомуми күләменең 20 проценттан артмаганын раслау рөхсәт ителә.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 137 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән тәртиптә бирелә торган дотацияләрдән тыш, Мөслим муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр хисаплы бюджет тәэмин ителеше әлеге муниципаль районның авыл җирлекләренен бюджет тәэмин ителешен тигезләү критериесе буларак билгеләнгән дәрәҗәдән артмаган авыл җирлекләренә бирелә. Җирлекләрнең хисаплы бюджет тәэмин ителеше салым базасыннан (салым потенциалыннан) чыгып авыл җирлеге бюджеты тарафыннан алынырга мөмкин булган бер кешегә салым керемнәре нисбәте һәм, халык структурасында, социаль-икътисадый, климатик, географик һәм башка объектив факторларда аермаларны һәм бер кешегә исәпләгәндә муниципаль хезмәт күрсәтүләр бәясенә йогынты ясый торган шартларны исәпкә алып, Мөслим муниципаль районы җирлекләре буенча уртача шундый ук күрсәткеч белән билгеләнә. Бюджет тәэмин ителешенең исәп-хисап дәрәҗәсе авыл җирлекләре буенча авыл җирлекләренең салым керемнәре чагыштырмасын тәэмин итә торган бердәм методика буенча, бюджет хезмәтләре исемлеге һәм бер кешегә исәпләгәндә муниципаль хезмәтләр күрсәтү бәясенә тәэсир итә торган факторларны һәм шартларны характерлый торган күрсәткечләр исемлеге буенча билгеләнә, авыл җирлекләре өчен аерым билгеләнергә мөмкин.

Җирлекләрнең хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен билгеләгәндә, хисап чорында фактдагы керемнәр һәм чыгымнар күрсәткечләрен һәм (яисә) аерым җирлекләрнең фаразлана торган керемнәре һәм чыгымнары күрсәткечләрен куллану рөхсәт ителми.

Россия Федерациясе Бюджет кодексынын 142.1 статьясындагы 4 пунктында каралган дотацияләр бирелгән очракта, Мөслим муниципаль районының финанс органы Мөслим муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр алучы авыл җирлекләре башлыклары белән җирлекнең социаль-икътисадый үсеше һәм муниципаль финансларын савыктыру чаралары каралган килешүләр төзергә хокуклы.

Әлеге пунктта күрсәтелгән килешүләр төзү тәртибе, вакытлары һәм

килешүләргә таләпләр Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының норматив документы белән билгеләнә.

2) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 статьясы нигезендә авыл җирлекләре бюджетларына финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешле субсидияләр торган башка бюджетара трансфертлар күрсәтелергә мөмкин.

Башка бюджетара трансфертлар чыгым йөкләмәләрен үтәү максатларында бирелә. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты бюджет акчаларының баш бүлүчесе булып тора. Башка бюджетара трансфертлар Мөслим муниципаль районы бюджетында тиешле финанс елына һәм чыгым йөкләмәләре нигезендә каралган максатларга Мөслим район Башкарма комитетына билгеләнгән тәртиптә житкерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

Башка бюджетара трансфертлар билгеләнгән критерийларга җавап бирә торган авыл җирлекләре бюджетларына бирелә.

Башка бюджетара трансфертларны бирү һәм тоту шартлары түбәндәгеләр:

а) башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү төзү

б) Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясында каралган Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бюджетара трансфертлар бирүнен төп шартларын авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары тарафыннан үтәү;

Башка бюджетара трансфертлар алу өчен, җирлек Башкарма комитеты, район Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән вакытларда, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетына Мөслим муниципаль райлны Башкарма комитеты раслаган форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирүгә гариза тапшыра.

Җирлек бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертларнын күләме билгеләнгән тәртиптә исәпләнгән формула буенча билгеләнә.

Җирлекләр бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертларны бүлү Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хокукый акты белән раслана.

Башка бюджетара трансфертлар бирү Мөслим район Башкарма комитеты тарафыннан расланган формаларда Мөслим район Башкарма комитеты һәм җирлек Башкарма комитеты арасында төзелгән башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Килешүдә карала:

– башка бюджетара трансфертларнын күләме, аларнын максатчан билгеләнеше;
– башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе;
– башка бюджетара трансфертларны бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренен әһәмияте;
– башка бюджетара трансфертлардан файдалану һәм башка бюджетара трансфертларны бирүнен нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыру сроклары һәм формалары;
– башка бюджетара трансфертларны алучынын билгеләнгән башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелегенең билгеләнгән күрсәткеченә ирешмәү нәтиҗәләре;
– бюджетара трансфертларны алучынын килешүдә каралган йөкләмәләрнен

үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

– килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы.

Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

– чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) бюджет турындагы карар нигезендә беркетелгән керем чыганакларының һәм бюджетара трансфертларның муниципаль район бюджетыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәк булган чыгымнар күләменә карата нисбәте 100 проценттан да ким булмаган җирлекләр саны;

– муниципаль бурыч алулар бирү елында бюджетны үтәү барышында башка бюджетара трансфертларны бирү вакытында башка бюджетара трансфертларны гамәлгә ашырмаган җирлекләр саны.

Нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешүне бәяләү вәкаләтле орган тарафыннан тапшырылган хисаплылыкка үткәрелгән анализ нигезендә Башкарма комитет тарафыннан башкарыла.

Авыл җирлеге Башкарма комитеты Мөслим район Башкарма комитетына килешүдә каралган форма һәм тәртип буенча башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыра.

Башкарма комитетка тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык җирлек башкарма комитетына йөкләнә.

Башка бюджетара трансфертлар Башкарма комитет тарафыннан җирлекләрнең бюджетына, килешүдә билгеләнгән срокларда, җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган Федераль казначылыкнын Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары счетларына күчерелә.

Башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль район бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

Башка бюджетара трансфертларны бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларнын калган өлеше, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, Балтач муниципаль районы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертлар максатчан характерга ия һәм башка максатларда кулланыла алмый.

Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын закон нигезендә Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Мөслим муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы контрольдә тота.

3) Россия Федерациясе Бюджет Кодексынын 133 статьясы нигезендә авыл җирлекләре бюджетларына тапшырылган Россия Федерациясе яисә Россия Федерациясе субъекты вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанс ягыннан тәэмин итү максатларында субвенцияләр бирелергә мөмкин.

Җирлекләр бюджетлары арасында субвенцияләрне бүлү Совет карары белән раслана.

Җирлекләр бюджетларына аерым чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бирелә торган субвенцияләр җирлек бюджетына күчерелә һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә чыгым йөкләмәләрен финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып тора.

Җирлекләр бюджетларына субвенцияләр тиешле йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру нормативларын исәпкә алып, бердәм методика

буенча җирлекләр арасында бүленә.

4) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясы нигезендә Мөслим муниципаль районы авыл җирлекләре бюджетларына Мөслим муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирелергә мөмкин.

Субсидияләр Мөслим муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджеты турында карары белән расланган Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында бирелә.

Субсидияләрнең максатчан билгеләнеше, субсидияләр бирү кагыйдәләре белән һәм мөслим муниципаль районы җирлекләренен финанслашулары өчен субсидияләр каралган чыгым йөкләмәләреннән чыгып, килешүләр белән билгеләнә.

5) башка дәрәҗәдәге хакимият органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен авыл җирлекләре дәрәҗәсендә чыгымнарның аерым төрләрең гамәлгә ашыру өчен региональ һәм муниципаль программалар буенча аерым чараларны үтәүгә акчалар, район бюджетыннан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан тапшырылган акчалар күләмендә күчерелә.

Авыл җирлекләре бюджетларына муниципаль район бюджетыннан тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар күләме һәм авыл җирлекләре белән бүлешү билгеләнгән тәртиптә һәм билгеләнгән методика нигезендә башкарыла.

6) Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасынын тиешле законнары нигезендә кабул ителә торган Мөслим муниципаль район Советының муниципаль хокукый актларында каралган очракларда һәм тәртиптә авыл җирлекләре бюджетларына төзелгән килешүләр нигезендә муниципаль районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга муниципаль район бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирелергә мөмкин.

Муниципаль район бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертларнын күләме һәм шәһәр һәм авыл җирлекләре арасында бүленеш билгеләнгән тәртиптә һәм билгеләнгән методика нигезендә башкарыла.

Муниципаль район бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертларның күләме Мөслим муниципаль район Советынын чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджеты турындагы карары, шулай ук Мөслим муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына муниципаль район бюджеты турындагы карарына үзгәрешләр кертү турындагы карарлары белән билгеләнә.

4. Муниципаль район бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар, Мөслим муниципаль районының авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджет законнарын, салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнарын үтәү шарты белән, төзелгән килешүләр нигезендә, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бүтән бюджетара трансфертлардан тыш бирелә.

Авыл җирлекләре Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджет

законнарын, муниципаль берәмлекләр өчен Россия Федерациясе Бюджет кодексынын 136 статьясында билгеләнгән чикләүләрне, бюджетара трансфертлар бирү максатларын үтәмәгән очракта, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 92.1 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән ин чик күрсәткечләрне бозганда, бюджетара трансфертлар бирү Мөслим муниципаль районының финанс бюджет палатасы тарафыннан туктатылып тора.

Мөслим муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар бирү, муниципаль район бюджетының финанс мөмкинлекләре һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар, шул исәптән, бюджет тәэмин ителешен тигезләү максатларында авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр бирү исәбеннән Мөслим муниципаль районы бюджетының үз керемнәре исәбенә гамәлгә ашырыла. Агымдагы финанс елында күрсәтелгән максатларга тотылмаган максатчан билгеләнеше булган бюджетара трансфертларның калган өлешләре шул максатларга чираттагы финанс елында файдаланылырга тиеш яисә Мөслим муниципаль районы Советынын чираттагы финанс елына Мөслим муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә муниципаль район бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Приложение 1

Методика
РАСПРЕДЕЛЕНИЯ ДОТАЦИЙ ИЗ
РАЙОННОГО ФОНДА ФИНАНСОВОЙ ПОДДЕРЖКИ ПОСЕЛЕНИЙ
входящих в состав Муслюмовского муниципального района

1. Средства районного фонда финансовой поддержки поселений (далее - РФФПП) распределяются между поселениями, входящими в состав муниципального района, на основе сопоставления уровня расчетной бюджетной обеспеченности поселений и аналогичного среднего показателя по всем поселениям муниципального района.

2. Уровень расчетной бюджетной обеспеченности поселения рассчитывается как соотношение его налогового потенциала к аналогичному показателю, рассчитанному по всем поселениям, входящим в состав муниципального района, в расчете на одного жителя, с учетом объективных факторов и условий, влияющих на стоимость предоставления бюджетных услуг. Уровень расчетной бюджетной обеспеченности j-го поселения рассчитывается по формуле:

$$БО^{j}_{расч} = \frac{УНП^{j} \times \mathrm{SUM}_{j=1}^{n} Ч_{j}}{ИБР^{j} \times Ч^{j} \times \mathrm{SUM}_{j=1}^{n} УНП_{j}},$$

где:

$БО^{j}_{расч}$ - уровень расчетной бюджетной обеспеченности j-го поселения;

$УНП^{j}$ - налоговый потенциал j-го поселения;

$ИБР^{j}$ - индекс бюджетных расходов j-го поселения, рассчитываемый в соответствии с порядком, установленным приложением 6 к настоящему Кодексу;

$Ч^{j}$ - численность населения j-го поселения;

n - число поселений муниципального района.

3. Условный налоговый потенциал j-го поселения муниципального района рассчитывается по формуле:

$$УНП^{j} = k^{j} \times УНП,$$

где:

$УНП^{j}$ - условный налоговый потенциал j-го поселения;

УНП - условный налоговый потенциал муниципального района, рассчитываемый в соответствии с порядком, установленным приложением 7 к настоящему Кодексу;

$k^{j}$ - коэффициент, учитывающий долю условного налогового потенциала j-го поселения в налоговом потенциале района.

4. Средства РФФПП распределяются комбинированным способом. Первая часть средств фонда распределяется с использованием метода пропорционального выравнивания бюджетной обеспеченности; вторая часть - с использованием метода выравнивания до "гарантированного минимума".

$$D^j = D^j_1 + D^j_2,$$

где:

$D^j$ - общий объем дотаций из РФФПП j-му поселению;

$D^j_1$ - объем части дотаций j-му поселению, распределение которой осуществляется методом пропорционального выравнивания;

$D^j_2$ - объем части дотаций j-му поселению, распределение которой осуществляется методом выравнивания до "гарантированного минимума".

5. Соотношения между частями РФФПП, распределяемыми тем или иным методом, определяются ежегодно при составлении проекта бюджета муниципального района на очередной финансовый год.

6. Распределение части средств РФФПП с использованием метода пропорционального выравнивания бюджетной обеспеченности осуществляется по формуле:

$$D^j_1 = d_{ПП} \times V_{ФФПМР} \times \frac{H^j}{H},$$

где:

$D^j_1$ - объем части дотаций j-му поселению, распределение которой осуществляется методом пропорционального выравнивания;

$d_{ПП}$ - доля РФФПП, распределение которой осуществляется с использованием метода пропорционального выравнивания;

$V_{ФФПМР}$ - объем РФФПП муниципального района;

$H^j$ - объем средств, необходимых для достижения j-ым поселением уровня бюджетной обеспеченности, установленного в качестве критерия выравнивания бюджетной обеспеченности;

H - объем средств, необходимых для достижения всеми поселениями уровня бюджетной обеспеченности, установленного в качестве критерия выравнивания бюджетной обеспеченности.

7. Определение объема средств, необходимых для достижения j-ым поселением уровня бюджетной обеспеченности, установленного в качестве критерия выравнивания бюджетной обеспеченности, осуществляется по формуле:

$$H^j = ИБР^j \times Ч^j \times (K - БО^j_{расч}) \times \frac{\sum_{j=1}^{n} УНП_j}{\sum_{j=1}^{n} Ч_j},$$

где:

$Н^{j}$ - объем средств, необходимых для достижения j-ым поселением уровня бюджетной обеспеченности, установленного в качестве критерия выравнивания бюджетной обеспеченности;

$ИБР^{j}$ - индекс бюджетных расходов j-го поселения, рассчитываемый в соответствии с порядком, установленным приложением 6 к настоящему Кодексу;

$Ч^{j}$ - численность населения j-го муниципального образования;

К - критерий выравнивания бюджетной обеспеченности;

$БО^{j}_{расч}$ - уровень расчетной бюджетной обеспеченности j-го поселения;

$УНП_{j}$ - условный налоговый потенциал j-го поселения;

n - число поселений, получающих дотации из РФФПП.

8. Критерий выравнивания расчетной бюджетной обеспеченности поселений определяется ежегодно при составлении проекта бюджета муниципального района на очередной финансовый год с учетом разницы в оценках суммарных потребностей и доходных возможностей поселений.

9. Объем средств, недостающих для достижения поселениями уровня бюджетной обеспеченности, установленного в качестве критерия выравнивания бюджетной обеспеченности, рассчитывается только по тем поселениям, уровень бюджетной обеспеченности которых меньше критерия выравнивания бюджетной обеспеченности (БОj < К).

10. После распределения первой части средств РФФПП определяется достигнутый уровень бюджетной обеспеченности поселений, который используется при распределении второй части средств РФФПП, рассчитываемый по следующей формуле:

$$БО^{j}_{1} = БО^{j} + \frac{Н^{j} \times \sum_{j=1}^{n} Ч_{j}}{ИБР^{j} \times Ч^{j} \times \sum^{n} УНП},$$